# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлегенә кергән Татар Такталы  торак пунктында 2024 елга үзара салым кертү турында

27.10.2023 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы  торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАРЫ:

1.Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы  авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Татар Такталы  торак пунктында  юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында рөхсәтсез барлыкка килгән чүплекләрне бетерү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында үзәк су белән тәэмин итү системасын юдырту( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы торак пунктында суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау һәм кое урнаштыру( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм http:// www. spasskiy.tatarstan.ru  Спас муниципаль районы рәсми сайтының Аграмак авыл җирлеге битендә, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru)  кабул ителгәннән соң10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ